ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ПОЛЯНКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР

20.10.2020 ел. № 4-2

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Полянка авыл җирлеге Советының "Полянка авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында" 07.10.2009 ел, № 72-2 карары белән расланган Полянка авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында" ( 29.01.2020 № 79, 16.06.2020 № 87-1 үзгәрешләр белән )

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 31 июлендәге 263-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Полянка авыл җирлеге советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Полянка авыл җирлеге Советының "Полянка авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында" 07.10.2009 ел, № 72-2 карары белән расланган Полянка авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә ( 29.01.2020 № 79, 16.06.2020 № 87-1 үзгәрешләр белән ):

1.1. 10 статьяның 2 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

1.2. Нигезләмәнең 34 статьясындагы 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Авыл җирлеге Советының керемнәренең гомуми күләмен үзгәртүгә китерә торган һәм бюджет турындагы карар проектын җирлек Советына керткәннән соң кабул ителгән норматив хокукый актларының нигезләмәсе агымдагы финанс елына һәм план чорына бюджетка үзгәрешләр керткәндә, агымдагы финанс елы күрсәткечләре өлешендә чираттагы финанс елында исәпкә алына.».

2. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Иске Рәҗәп авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http://www.spasskiy.tatarstan.ru) һәм хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (//http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Полянка авыл җирлеге башлыгы: Г.Г. Сибгатуллина

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «ПОЛЯНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА» СОВЕТ ПОЛЯНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ